СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.07.2020 Баулы шәһәре № 272

Баулы муниципаль районы Советының 2005 елның 13 декабрендәге «Баулы муниципаль районы Советы регламенты турында»гы 3/2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы шәһәр Советы утырышларын югары әзерлек, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәл режимнары чорында уздыру максатларында Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2005 елның 13 декабрендәге «Баулы муниципаль районы Советы регламенты турында»гы 3/2 номерлы карарына (2010 елның 25 февралендәге 238 номерлы, 2012 елның 13 июнендәге 113 номерлы, 2014 елның 4 апрелендәге 200 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3нче статьяга түбәндәге эчтәлекле 4нче пункт өстәргә:

«4. Югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яисә хәрби хәл чорында, Баулы муниципаль районы Советы утырышы әлеге пунктта билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре яисә видеоконференцэлемтә

каналлары чараларыннан файдаланып, дистанцион рәвештә үткәрелергә мөмкин.

Совет утырышында карарлар дистанцион формада ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорауларга язылу, чыгышка язылу утырышта катнашучы депутатлардан сораштыру юлы белән (Совет депутатлары тарафыннан билгеләнгән башка ысуллар белән, дистанцион формада) үткәрелә.

Совет утырышын дистанцион рәвештә уздырганда утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, ул утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана. Совет утырышы беркетмәсенә дистанцион рәвештә утырышны уздырганда кулланыла торган программа чаралары, утырышның башлану һәм тәмамлану вакыты турында белешмәләр, шулай ук әлеге Регламентта каралган башка белешмәләр кертелә.»;

16 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчада «район үсеше планнары һәм программалары проектларын эшләүдә катнаша» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслауда катнаша» сүзләренә алмаштырырга;

32 статьяның 2 пунктында «районны үстерү программаларын» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 38.1 статья өстәргә:

«1. Район прокуроры, шулай ук законнар, «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы тарафыннан вәкаләтле башка вазыйфаи затлар Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында район халкы һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Башкарма комитет хезмәткәрләре Совет алар карамагындагы мәсьәләләрне караганда ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр депутатларның гомуми саныннан абсолют күпчелеге җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары утырышында катнашу тәкъдимен кабул итсә,

Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары утырышында катнашуны таләп итәргә хокуклы.

Совет рәисе тарафыннан утырышка чакырылган вазыйфаи затка чакыру утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, утырышны үткәрү вакыты, урыны, шулай ук күрсәтелгән вазыйфаи зат Совет утырышына чакыруга сәбәп булган мәсьәләне күрсәтеп җиткерелә.

5. Совет рәисе утырыш башланыр алдыннан утырышта катнашучылар Совет депутатлары булмаган затлар турында хәбәр итә.

6. Утырышка чакырылган һәм утырышта катнашкан затлар Совет эшенә катышырга (чыгыш ясарга, сүз алырга, хуплау яки канәгатьсезлек белдерергә) хокуклы түгел.

7. Совет карары буенча, чакырылган затларга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.».

82 статьяның 1 пунктында «районны үстерү планнары һәм программалары» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен раслау» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www:pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (www: bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе — Р.Х. Гатиятуллин